**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_04__» ____04___ 2023 ел** **№ ___79__**

Азнакай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторын беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын расларга.

2. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1

гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. «Азнакай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 ноябрендәге 353 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Азнакай муниципаль районы сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанс буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты карарына кушымта
"______" ________ 2023 ел № _____

Азнакай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторын беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә эшләнде, һәм Азнакай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү механизмын һәм срокларын билгели (алга таба - исемлек, баш администратор).

2. Азнакай муниципаль районы бюджеты керемнәре классификациясенең баш администраторларына беркетелгән кодлар исемлегенә үзгәрешләр «Азнакай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының «Азнакай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге турында» 2022 елның 14 декабрендәге 392 номерлы карарына үзгәрешләр кертмичә генә «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МКУ боерыгы нигезендә кертелә:

2.1. Азнакай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторларына беркетелгән составлары үзгәргәндә;

2.2. ачыкланмаган түләүләрне ачыклау өчен расланган исемлектә булмаган түләүләр кергән очракларда.

3. Исемлеккә үзгәрешләр, исемлеккә үзгәрешләр кертү өчен 2 пунктта күрсәтелгән нигезләр барлыкка килгән көннән алып 5 (биш) эш көне эчендә кертелә.